**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Мюд авыл җирлеге башкарма комитеты**

# КАРАР

. № 10 23.08.2018 ел.

**«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2014 елның 01 июнендәге 3 номерлы Мюд авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

1. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 27.11.2017 ел, № 355-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы прокуратурасының 23.07.2018 ел, №02-08-02-18 протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:
2. "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында"01.06.2013 ел, № 5 Мюд авыл җирлеге Башкарма комитетының карарына 1,2,3,4,5 кушымталарында түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**3. 5нче Бүлектә 5.1 пунктны түбәндәге эчтәлекле пунктлар белән тулыландырырга:**

8) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;
9) әгәр туктату нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне туктатып тору.
2. «Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты» 5 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

**«6. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау.**

1.Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләренә коррупция һәм талау фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу, шулай ук хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган башка гамәлләр кылу турында белешмәләр керә.
2. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатен караганда мөрәҗәгатьләрдәге мәгълүматларны, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы мәгълүматларны аның ризалыгыннан башка таратырга ярамый. Мөрәҗәгатьтәге мәгълүматларны тарату түгел, мөрәҗәгать итүдә куелган мәсьәләләрнең барлык шартларын ачыклаганчы хәл итү аның компетенциясенә керә торган вазыйфаи затка язмача мөрәҗәгать итү.
3. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатен исәпкә алу, теркәү, карау барышы гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү, мөрәҗәгатьне «коррупция»категориясенә кертү өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан башкарыла.
4. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләре системалы рәвештә анализлана һәм гомумиләштерелә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubayevo.tatarstan.ru.и Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru)Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Мюд авыл җирлеге башлыгы
Башкарма комитет җитәкчесе Т.В. Зюзина